ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматы хакында

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил – Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе Ф.С. Габделганиевнның (алга таба – Вәкаләтле вәкил) 2024 елда үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елда Вәкаләтле вәкилнең үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Вәкаләтле вәкилнең эшкуарлык эшчәнлеге субъектларының хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауга юнәлтелгән эшенең системалы, шул исәптән судта яклауда катнашу һәм консультация рәвешендә хокукый ярдәм күрсәтү юлы белән, алып барылуын билгеләп үтәргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, җирле үзидарә органнарына 2024 елда Вәкаләтле вәкилнең үз эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүматында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру буенча чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

4. Вәкаләтле вәкилгә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. Татарстан Республикасында эшкуарлык климатын яхшыртуга юнәлтелгән эшне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы бизнес-берләшмәләре белән хезмәттәшлектә дәвам итәргә.

4.2. Эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләләренә кагылышлы норматив хокукый актларга даими нигездә мониторинг ясауны һәм аларның хокук куллану тәҗрибәсен бәяләүне үткәрергә, аннары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына эшкуарлык эшчәнлеген норматив хокукый җайга салуны, шулай ук тиешле

хокук куллану тәҗрибәсен камилләштерү турында кызыксындыргыч тәкъдимнәрне юлларга.

4.3. Түбәндәгеләрнең нәтиҗәлелеген арттыру эшен көчәйтергә:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлектә кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мәнфәгатьләрен яклау һәм аларның законлы хокукларын торгызу чараларының;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөрәҗәгатьләрен, шикаятьләрен карауның;

муниципаль районнарда һәм шәһәр округларында җәмәгатьчелек вәкилләре институты эшчәнлегенең;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына карата тикшерү чараларын үткәрүгә ихтималлык ягыннан якын килүне тәэмин итү өчен контроль-күзәтчелек органнары белән хезмәттәшлекнең.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитетына Вәкаләтле вәкил белән берлектә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына дәүләт преференцияләрен бирү өлешендә, шулай ук Вәкаләтле вәкил эшчәнлеген җайга салу өлкәсендә законнарны камилләштерү эшен дәвам итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары М.Г. Әхмәтовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 323-VII ДС